**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге составына керүче Таулы Дөреш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

14 ноябрь, 2025 ел № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы «Иске Дөреш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Иске Дөреш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Советының 2019 елның 31 октябрендәге 8/1 номерлы карары нигезендә 2025 елның 13 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елның 25 октябрендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча уздырылган гражданнар җыены йомгаклары буенча җыелган акчалар исәбенә ***«торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Таулы Дөреш авылының Ленин урамындагы юл чокырларын ремонтлау)»*** эш төрен ***«торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (традицион күмү урынына бара торган юл өчен вак таш сатып алу)»*** эш төренә үзгәртергә ризамы?»

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 55 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 30 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 30 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Таулы Дөреш авыл җирлеге Таулы Дөреш авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «Сез 2024 елның 25 октябрендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча уздырылган гражданнар җыены йомгаклары буенча җыелган акчалар исәбенә ***«торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Таулы Дөреш авылының***

***Ленин урамындагы юл чокырларын ремонтлау)***» эш төрен ***«торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (традицион күмү урынына бара торган юл өчен вак таш сатып алу)***» эш төренә үзгәртергә ризамы?» - мәсәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Иске Дөреш авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, өлешчә мобилизацияләү буенча РФ Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, котнтракт төзегәннәрне, доброволецларны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә.

4. Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Таулы Дөреш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

5. Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Таулы Дөреш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Дөреш авыл җирлеге Башлыгы Р.М. Дусадбеков